**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Чепья авыл җирлеге составына керүче Тагашур авылы торак пунктында

11 ноябрь 2022 ел № 6

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Тагашур авылында гражданнар җыены карар итте:

1. 2023 елда Балтач районы Чепья авыл җирлегенең Тагашур авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән; 50 процент күләмендә ташлама каралган 1 төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк өлкән пенсионерлардан, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче тулы булмаган гаиләләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 600 сум күләмендә үзара салым акчасы җыярга.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- янгынга каршы гидрантка бер комплектлы әйбер сатып алу;

- ял паркын планлаштыру һәм коймалау, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру.

3. Җыенның нәтиҗәләрен кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Чепья авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендэ игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Чепья авыл җирлеге башлыгы А. Г. Нотфуллин